БОЕРЫК
18.12.2018

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
________

Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге территориясендә салют үткәрү урынын билгеләү турында

Яңа ел бәйрәм чараларының, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге буенча янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, «РФ җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 313-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 07 декабрендәге 1088 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2018 елның 20 декабреннән 2019 елның 9 гыйнварына кадәр Актаныш муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертергә.
2. Пиротехник эшләнмәләрдән файдаланып салют үткәрү өчен урыннар (мәйданчыклар), социаль даирәнең якындагы торак объектларына түбәндәге таләпләргә туры килә торган ераклыкны билгеләргә:

а) Актаныш авылының Җиңү паркында;

б) «Агыйдел «җыр һәм бию ансамбле»бинасы каршындагы мәйданда.

3. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда пиротехник эшләнмәләр куллану тыелган объектларның кушымтада бирелгән исемлеген, 1 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Яңа ел салютын уздыруны оештыручылар РФ законнары нигезендә административ җаваплылыкка тартыла дип билгеләргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш авыл башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ш.Шәрипов

Актаныш муниципаль районы
Актаныш авылы Башкарма комитетының
2018 елның 18 декабрендәге карарына
1 нче кушымта

Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган
чорда пиротехника әйберләрен куллану тыелган объектлар исемлеге

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Сәнәгать объектлары: | - төзелеш сәнәгатен оештыру |
| 2 | Торак-коммуналь хуҗалык объектлары: | - торак фонды,<br>- халыкны газ, җылылык һәм электр белән тәэмин итү объектлары |
| 3 | Авыл хуҗалыгы объектлары: | - хайваннары булган хуҗалыклар;<br>- ашлык саклагычлары;<br>- агулы химикатлар һәм минераль ашламалар саклау складлары;<br>- орлык эшкәртү һәм агулау предприятиеләре;<br>- терлек азыгы әзерләү цехлары; - йөк автомобильләрен һәм авыл хуҗалыгы техникасын ремонтлау, технологик хезмәт күрсәтү һәм саклау буенча гаражлар һәм парклар; - матди складлар. |
| 4 | Кешеләр күп була торган объектлар: | - дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының административ биналары,<br>- Мәдәният, спорт, мәгариф, сәламәтлек саклау объектлары - кибетләр. |